СОВЕТ
СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с. Старое Дрожжаное **КАРАР**

15.11.2022г. № 26/2

Җирле салымнар буенча түләнеп бетмәгән салымнарны, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, җирле салымнар буенча түләнеп бетмәгән салымнарны, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүне өметсез дип тану буенча өстәмә нигезләр билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле салымнар буенча түләнеп бетмәгән салымнарны, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану өчен түбәндәге өстәмә нигезләрне билгеләргә:

1.1. Үлем көненнән 6 ай эчендә мирас хокукы теркәлмәгән очракта, вафат булган яки үлгән дип игълан иткән физик затларда түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар бурычы булу;

1.2. җирле салымнар буенча 3 елдан артык бурыч барлыкка килү срогы белән;

1.3. Россия Федерациясе законнары нигезендә бетерелгән оешмаларның түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлары булу;

1.4. салым органнары тарафыннан әлеге түләнеп бетмәгән салымнарны, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны суд приставы тарафыннан «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге №229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пуктларында каралган нигезләр буенча башкарма производствоны тәмамлау турында карар чыгаруга бәйле рәвештә түләттерү мөмкин булмаган очракта, уңышсызлык турындагы (банкротлык) эшендә кулланыла торган процедураларда булмаган салым түләүчеләрдә түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар булу;

1.5. 2022 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча салым түләүчеләр өчен исәпләнгән түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар булу;

1.6. бурыч барлыкка килгәннән бирле аны түләү буенча 3 елдан артык вакыт узып, бурычлының түләтү мөмкинлеге бирелгән мөлкәте булмаганда, Россия Федерациясеннән читкә киткән физик затларда түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар булу;

1.7. бу түләнеп бетмәгән салымнарны түләтү срогы чыкканнан соң түләнеп бетмәгән салымнарга исәпләнгән оешмаларда пенялар буенча бурычлар булу;

1.8. суд тәртибендә яраксыз дип танылган, психик бозылышлары булган затлар буенча түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар булу;

1.9. өлкәннәр (ветераннар)йортларында яшәүче затларга түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар булу;

1.10. Башкарма комитет раслаган очракта, аз керемле физик затларның түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар булу;

1.11. суд карары нигезендә һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булган затларга түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар булу.

2. Салым түләүченең бурычын гамәлдән чыгару салым органы тарафыннан әлеге карар һәм салым түләүченең бурычы турындагы белешмә нигезендә башкарыла.

3. Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 2013 елның “7” мае 32/1 номерлы карары «Җирле салымнарның түләнеп бетмәгән салымнарны, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында».

4. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://drogganoye.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Иске Чүпрәле авыл җирлеге
Башлыгы Урынбасары: Р.Д.Низамов